РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Әхмәт ав. КАРАР

2 ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Ерепкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 17 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Ерепкино авылы, Киров урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ерепкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ерепкино авылының Беренче Май урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Ерепкино авылы, Киров урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ерепкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Иванов урамындагы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 17 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Ерепкино авылы, Киров урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ерепкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Киров һәм Новая урамнарындагы йортларда яшәүчләр өчен гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Ерепкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан,

бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ерепкино авылы чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;
- Ерепкино авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу;
- гражданнардан зиратларны төзекләндерүгә һәм карап тотуга 2016 елда җыелган һәм 2017 елда 55000 сум күләмендә финансланган үзара салым акчаларын Ерепкино авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлауга һәм карап тотуга юнәлдерергә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ерепкино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Шәйхетдинов